Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2023 елның 18 ноябре №4

2024 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлеге Югары Чыршылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2023 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлеге Югары Чыршылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, сроклы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум (Биш йөз) күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

Югары Чыршылы авылында урам яктыртуга техник хезмәт күрсәтү: Югары урам, Тау урамы, Рудничная урамы, Үзәк урам.

2)торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Югары Чыршылы авылында Югары, Үзәк урамнары буенча вак таш юлларны чокырлы ремонтлау.

Югары Чыршылы авылында Югары урам, Тау урамы, Рудничная урамы, Үзәк урам буенча юлларны кардан чистарту

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Түбән Чыршылы авылы административ бинасында-Үзәк урам, 105 йорт, балалар бакчасы бинасында -Совет урамы, 8 йорт, Үзәк урам, 23 йорт буенча, «АФ-Спартак» ҖЧҖ идарәсе бинасында-Совет урамы, 2 йорт , Мордва Ивановка авылында-авыл клубы бинасында-Горная урамы, 27 йорт, Мордва Ивановка авылында Совет урамы 13 йорт буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Н.Я. Хәйруллина